ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОХАРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОХАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«19» ноября 2025г** **№16**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохар авыл җирлеге территориясендә шундый корылмалар һәм (яисә) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен кую һәм (яисә) саклау өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштырылырга мөмкин булган объектлар төрләре исемлеген раслау турында» 03.12.2014 ел, № 1300 карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «объектларны урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында " 05.06.2015 ел, № 416 Карары нигезендә җирләрендә яисә җир кишәрлекләрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган, Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге, җир кишәрлекләре бирелмичә һәм сервитутлар, гавами сервитут билгеләмичә», Зәй муниципаль районы Бохар авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохар авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохар авыл җирлеге территориясендә шундый корылмалар һәм (яисә) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен кую һәм (яисә) саклау өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2.Әлеге карарны җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе Е.В. Груздева

Кушымта
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Бохар авыл җирлеге башкарма комитеты карарына
«19» ноябрь 2025 № 16

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бохар авыл җирлеге территориясендә шундый корылмалар һәм (яисә) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен куюны оештыру һәм (яисә) саклау өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары

| № п/п | Объектның урнашу урыны | объект мәйданы кв. м | объектның урнашу координаталары |
|---|---|---|---|
| 1 | Зәй районы, Бохар авылы, Мэктэп ур., 12 йорт | 6 | 55.145154,52.319266 |
| 2 | Зәй районы, Бохар авылы, Мэктэп ур., 13А йорт | 4 | 55.143873,52.318493 |